СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д. 13, д.Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр урамы, 13 йорты, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366)53-4-32, факс (84366)53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Урта Курса авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**17.07.2026 ел** **№ 19**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең ирекле халык дружинасы төзелергә һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырга мөмкин булган территория чикләрен билгеләү турында**

“Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, “Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында” 2014 елның 02 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Урта Курса авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең ирекле халык дружинасы төзелергә һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырга мөмкин булган, үз эченә Урта Курса, Югары Курса, Түбән Курса,Алан, Сарай-Чокырча, Корайван авылы торак пунктларын алган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге чикләрен территория чикләре дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- “Халык дружинасы эшчәнлеге территориясе чиген билгеләү турында” 2014 елның 17 декабрендәге 35 номерлы;
- “Халык дружинасы эшчәнлеге территориясе чиген билгеләү турында” 2016 елның 17 ноябрендәге 32 номерлы;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина